ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 18 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 284**

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 30 июлендәге 432 номерлы
карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үткәрү турында Чистай шәһәре прокуратурасының 2022 елның 6 апрелендәге 02-01-17-2022 номерлы тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 432 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендәге 2.5.1 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) мондый объектны реконструкцияләгән очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең, күпфатирлы йортны үзгәртеп кору очракларының 6.2 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, бер үк вакытта блокланган төзелештәге бер йортны реконструкцияләгән очракта, барлык йортка ия булучыларның ризалыгы;»;

1.2. «1. Гомуми нигезләмәләр» 1.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча өстәргә:

«1.1) шәхси торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү ("Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш)»;

1.3. «1. Гомуми нигезләмәләр» бүлегендәге 1.5 пунктының 4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән әлеге Кодексның 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов